**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 10 июлендәге 2443 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Вахитов районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 1616 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлекләренең кадастр номерлары – 16:50:010623:44, 16:50:010623:442, 16:50:010623:444;

- хокуклар чикләнә торган кадастр кварталлары: 16:50:010623;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Вахитов районы, Бутлеров урамы;

- билгеләү максаты: 2026 елның 1 октябренә кадәр эшләр башкару чорына төзелеш техникасы өчен килү юлларын һәм материалларны вакытлыча саклауны тәэмин итү;

- билгеләү вакыты: 2026 елның 1 октябренә кадәр;

1.2. гариза бирүче: «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесе;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының V.7 бүлеге, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.37 статьясы.

2. Әлеге карарга 1 һәм 2 номерлы кушымталарда күрсәтелгән җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төре нигезендә файдалану мөмкин булмаячак яки сизелерлек кыенлашачак вакыт әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән ачык сервитут вакытына туры килә дип билгеләргә.

3. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны, 2 номерлы кушымтасыннан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының

рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

6. «Татарстан Республикасы Баш инвестиция-төзелеш идарәсе» дәүләт казна учреждениесенә түбәндәгеләрне үтәргә тәкъдим итәргә:

6.1. Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының 2025 елның 13 октябрендәге 1808 номерлы «Бөтендөнья мирасы, җирләрдән файдалануның махсус режимнары һәм әлеге зоналар территорияләре чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләр исемлегенә кертелгән «Казан кремле ансамбле», XV гасыр – XX гасырның беренче чиреге (Татарстан Республикасы (Татарстан) федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектын саклау зоналары чикләрен раслау турында»гы әмере (Россия Федерациясе Юстиция министрлыгында 2026 елның 29 гыйнварында 85129 номеры белән теркәлгән) белән расланган «Казан кремле ансамбле» федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектыннан файдалану режимнарын һәм аны саклау зоналары чикләрендә шәһәр төзелеше регламентларына карата таләпләрне;

6.2. «Казан шәһәре тарихи үзәгенең мәдәни катламы, XI-XVIII гасырлар» федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объекты чикләрендә Татарстан Республикасы Комитетының 2023 елның 1 декабрендәге 953-П номерлы әмере, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының 2010 елның 1 апрелендәге 183 номерлы «Истәлекле урыннар территориясен файдалануның характеры, әлеге территориядән файдалануга чикләүләр һәм Казан шәһәренең истәлекле урыннары территориясендә хуҗалык эшчәнлегенә, проектлауга һәм төзүгә таләпләр турында нигезләмәне раслау хакында»гы әмере белән билгеләнгән чикләүләрне;


6.3. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2024 елның 28 декабрендәге 749-П номерлы әмере белән расланган Казан шәһәренең төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлек территориясе чикләрен һәм сак предметын.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 10 июлендәге
2443 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## **Ачык сервитут йогынтысы өлкәсе чикләре**




| Масштаб 1:500<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:50:010623 | кадастр кварталы |
| 16:50:010623:44, 16:50:010623:442, 16:50:010623:444 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

_______________________________